Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Югары Акташ авыл Советы
КАРАРЫ

11 декабрендәге 2020 ел № 9

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл Советының 2020 елның 03мартындагы «Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлегенең пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә турында» 112 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 13 ноябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, хокукый мониторинг тәртибендә

Югары Акташ авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл Советының 2020 елның 03 мартындагы «Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлегенең пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә турында» 112 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга кушымтаны 6.1. пункты белән тулыландырырга:

«6.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән затка Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмаганда башкарыла.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынганда, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү шундый түләү сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.».

2. Әлеге карарны Югары Акташ авылы, Совет урамы, 15 нче йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Югары Акташ авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Югары Акташ
авыл җирлеге Башлыгы А.В.Шатунов